**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**9 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен**
**татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре**
**(2015/2016 нчы уку елы)**

**Үткәрү вакыты- 3 сәгать** **Максималь балл - 58**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Телнең сүз һәм кушымчаларны төзи һәм аларны бер-берсеннән аера торган иң кечкенә берәмлеген ничек атыйлар? ***(2 балл)***
   а) аваз;
   ә) фонема;
   б) иҗек;
   в) хәреф.

2. Татар алфавитында үз хәрефе булмаган авазны күрсәтегез. ***(2 балл)***
   а) [э];
   ә) [ч];
   б) [w];
   в) [к].

3. *“Әнә шул **ике пыяла** – завуч икән”, - дип уйлап алдык* (М.Мәһдиев) җөмләсендәге билгеләнгән сүз нәрсә була? ***(2 балл)***
   а) метафора;
   ә) метонимия;
   б) синекдоха;
   в) фразеологик әйтелмә.

4. *Туңа-туңа ашадык без*
   *Ширбәт салган зур **карбызны**.*
   *Җәй буена ничек кояш*
   *Эретмәгән бу **кар, бозны*** (Ш. Галиев) шигырендәге билгеләнгән сүзләр үзара нинди мөнәсәбәттә? ***(2 балл)***
   а) омоформалар;
   ә) омографлар;
   б) омофоннар;
   в) паронимнар.

5. Термин һәм аның мәгънәсен ачыклый торган төшенчәләрне, бер-берсенә туры китереп, цифрларны уртадагы графага языгыз. ***(6 балл)***

| | | |
|---|---|---|
| а) фонетик ысул | | (1) сүзләрне кушу |
| ә) морфологик ысул | | (2) тсүзгә яңа мәгънә өстәү |
| б) синтаксик ысул | | (3) сүзгә кушымчалар өстәү |
| в) конверсия ысулы | | (4) сүзне кыскарту |
| г) лексик-семантик ысул | | (5) сүзнең аваз составы үзгәрү |
| д) аббревиация ысулы | | (6) сүзнең бер сүз төркеменнән икенчесенә күчүе |

6. Фигыль ясаучы кушымчалардан торган төркемне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) -ай/-әй, -ы/-е, -лаш/-ләш, -ылда/-елдә;
ә) -ма/-мә, -гыч/-геч, -ык/-ек, -чан/-чән;
б) -лык/-лек, -ым/-ем, -ак/-әк, -ыш/-еш;
в) -лап/-ләп, -ча/-чә, -ык/-ек, -лата/-ләтә.

7. Ярым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган, үзен ияртүче сүздән ераклашкан хәл кисәкләрнең кайсы өтер белән аерылмый? ***(2 балл)***
а) вакыт хәле;
ә) урын хәле;
б) рәвеш хәле;
в) кире хәл.

8. Аныклагыч янында ике нокта куела торган очракны билгеләгез. ***(2 балл)***
а) аныклагыч аныкланмышка искәрмә рәвешендә килсә;
ә) аныклагыч та, аныкланмыш та исем белән белдерелсә;
б) аныкланмыш фигыль белән белдерелсә;
в) аныкланмыш рәвеш белән белдерелсә.

9. Күп нокталар урынына ике бертөрле хәреф куелмый торган очракны табыгыз, һәр сүзгә тиешле хәрефләрне куегыз. ***(2 балл)***
а) мөхә ... ир;
ә) тәкә...ер;
б) тәвә ... әл;
в) мөка ... әс.

10. Сүзгә кушымчаларның дөрес ялганган вариантын билгеләгез. ***(2 балл)***
а) календарь+ебез;
ә) календар+е+без;
б) календар+е+быз;
в) календар+ы+быз.

11. *Шуны истән чыгарма, улым (...) текә башлы булу гакылсызлыктан килә* (Дәрдемәнд) җөмләсендә тиешле тыныш билгесе: ... ***(2 балл)***
а) баш җөмлә белән иярчен җөмлә арасына куелган ике нокта;
ә) хәбәрлекләр арасына куелган өтер;
б) баш җөмлә белән иярчен җөмлә арасына куелган сызык;
в) каршы куелган хәбәрлекләр арасына куелган сызык.

12. Билгеләү алмашлыгы булган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) Каршыга берәү килә: ике кулына ике зур сумка тоткан.
ә) Өйдәгеләрнең барысы да минем фикерне хуплады.
б) Асыл сөяк зур булмас, кая барса да хур булмас.
в) Безнекеләр ни өчендер бернинди дә хәбәр белдермиләр.

13. Йөкләтү юнәлешендәге фигыльләр тупланган төркемне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) аралашу, уйлану, карау, җыелу;
ә) йөгерәчәк, юыныр, белер, күрәчәк;
б) күрсәтте, ямьләндерде, җиткерде, торгызды;
в) бизәлгән, төренгән, танылган, җигелгән.

14. *Бер төрле кешеләр бар (1) син аларга дус булсаң (2) алар каршында галим дә син (3) мөхәррир дә син (4) әмма бераз салкынлык булса (5) алар синдә булган фазыйләтне (6)*

*булдыклылыкны (7) уйларга да куркалар* җөмләсендә өтер куелырга тиеш урыннар дөрес күрсәтелгән төркемне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) 1,2,3,4,5,6,7;
ә) 2,3,4,5;
б) 1,3,4,5,6;
в) 2,3,4,5,6.

15. *Алар бер-берсенә шулкадәр охшаганнар: Гәүһәр әле булса аларны бутый* (Г. Әпсәләмов) җөмләсендәге иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) иярчен вакыт җөмлә;
ә) иярчен күләм җөмлә;
б) иярчен рәвеш җөмлә;
в) иярчен шарт җөмлә.

16. *Ямь ямь түгел,*
*шатлык шатлык түгел,*
*Син булмагач минем каршымда*
(Ә. Атнабаев)

җөмләсенең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
б) катнаш кушма җөмлә;
в) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

17. *Нурисламның тәне* ***эсселе-суыклы булып китте*** (Ф. Садриев) җөмләсендә билгеләнгән сүзләр җөмләнең кайсы кисәге булуын билгеләгез. ***(2 балл)***

а) хәбәр;
ә) рәвеш хәле+хәбәр;
б) күләм хәле+хәбәр;
в) аергыч+хәбәр.

18. *Тынып калды җәйрәп яткан үзәннәр* (И. Юзеев) җөмләсе – ***(2 балл)***

а) бер составлы тулы җөмлә;
ә) бер составлы ким җөмлә;
б) ике составлы тулы җөмлә;
в) ике составлы ким җөмлә.

## II Теоретик бирем.

Тел белеменең тыныш билгеләре һәм аларны кую кагыйдәләрен өйрәнә торган бүлеге ... дип атала. Җөмләләрдә тыныш билгеләрен кую төп ике принципка (нигезгә) таяна. Аларның беренчесе – ... , икенчесе – ... нигез. ***(3 балл)***

Татар телендә кулланыла торган тыныш билгеләре түбәндәгеләр: ... ***(5 балл)***

## III Иҗади бирем.

*Тормышта кайсы мөһимрәк: эш сөюме, әллә инде акыллы булумы?*

Шушы сорауны терәк фикер итеп алып, үз фикерләрегезне 13-14 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***